РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Совет
Сосновского сельского поселения
Нижнекамского муниципального района

423596, Нижнекамский район,
д. Благодатная, ул.Мира, 64

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Түбән Кама муниципаль районы
Сосновка авыл җирлеге
Советы

423596, Түбән Кама районы,
Благодатная авылы, Тынычлык урамы, 64

тел./факс (8555) 33-14-17, электронный адрес: Sosnovskoe.sp@tatar.ru,
сайт: www.sosnovskoe-sp.ru

## РЕШЕНИЕ КАРАР

11.06.2024 ел № 6

**Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычны түләтүгә ышанычсыз дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясындагы 3 пункты, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Түбән Кама муниципаль районының «Сосновка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы, Сосновка авыл җирлеге Советы карар бирә:

Аерым салым түләүчеләр өчен исәпләнүче 2024 елның 1 гыйнварына җирле салымнар суммалары өлешендә бурыч түләүгә ышанычсыз дип тануга өстәмә нигезләр билгеләргә:

1) варислар мираска хокуктан баш тарткан, варислар булмаган яисә мирас ачылган көннән бер ел дәвамында мирас кабул итмәгән очракта үлгән яисә вафат булган физик затларның бурычы булу;

2) оешмалар яисә индивидуаль эшкуарлар тарафыннан 2024 елның 1 гыйнварына кадәр юкка чыгарылган җирле салымнар буенча исәпләнелә торган бурыч булу;

3) физик затларның Россия Федерациясе Салым кодексының 48 статьясында билгеләнгән сроклар тәмамланганнан соң 500 сумнан артмаган суммада бурычы булу.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

А.Н.Бурчин